Казан шәһәре Совет районы “181 нче күп профильле мәктәп”
№7 март, 2020 ел

# «Күкнең җиденче катында»




8 март хатын – кызларны олылау көне, матурлык бәйрәме. Әлеге бәйрәм башка бәйрәмнәрдән яктырак та, җылырак та, мөлаемрак та шикелле. Шуңа күрә дә менә бу бәйрәмне кешелек дөньясы 1913 нче елдан ук бәйрәм итеп килә.

Сезне бөтен җир йөзен бизәгән яз бәйрәме – Халыкара хатын – кызлар көне белән тәбриклибез. Сезгә озын гомер, елмаеп балкыган кояш матурлыгы, укуыгызда зурдан – зур уңышлар телибез.

# Бәйрәм белән Сезне!

**Әни** – җирдә иң газиз, якын кеше. Ул сине тудырган, көйләп бишектә тирбәткән, синең беренче елмаюыңны, беренче әйткән сүзләреңне ишетеп сөенгән, тәпи атлап китүеңне күреп шатланган. Ул безне туган телебезне яратырга өйрәткән. Без үзебезнең тормышыбызны алардан башка күз алдына да китерә алмыйбыз. Алар – безнең дөньябызның яме, шатлыгы.

Һәркемнең тормышында иң изге кеше ул – әни. Чын күңелдән безне яратучы бердәнбер кеше дә – әни. Ялгышларыбызны, хаталарыбызны һәрдаим гафу итүче, кичерә белүче иң олы йөрәкле кеше дә – әни. Ничә яшебезгә җитсәк тә, безне сабый бала кебек кайгыртып, безнең өчен ут йотып яшәүче дә – әни. Дөньяга аваз салуга ук ул безне җил-яңгырдан саклап үстерә, олы тормыш юлына әзерли, акыллы киңәшләре белән ярдәм итеп тора.

Кадерле, сөйкемле әниләребез! Бәйрәм белән Сезне! Һәрвакыт матур, мөлаем булып калыгыз!

Безнең укытучыларыбызның күбесе-хатын-кызлар. Бу шаккатырлык та түгел, бары хатын-кыз гына бала белән уртак тел табып, аны аңлый, тынычландыра, төпле киңәшләрен бирә ала. Укытучы, икенче әни кебек, балаларны кыерсытырга юл куймас.

Без үз укытучыларыбызны хөрмәт итәргә тиеш, аларның эшләре бик катлаулы һәм җаваплы.

Һәр укучы үзенең беренче укытучысын, беренче дәресен, аның акыллы киңәшләрен хәтерли.

Укытучыларыбызны онытмыйк!

Хөрмәтле укытучыларыбыз! Сезне бәйрәм белән котлыйбыз!

**Март аенда, кар өстендә,**
**кояш нурлар уята –**
**Яз килә каршы алыгыз –**
**Дигән хәбәр тарата.**
**Без беләбез, җылы язның**
**Иң беренче бәйрәме –**
**Әниләр, әби-апалар**
**Хатын кызлар бәйрәме.**

# Мәктәбебез тормышы “кайнап” тора...

## Ярминкә

Мәктәбебез тормышы һәр көн шатлык китерергә тиеш. Моның өчен без үз тормышыбызны кызыклы итеп оештырырга тиешбез. Ә без шулай эшлибез дә!

6 нчы март көнне мәктәбебездә ярминкә булды. Ул, гадәттәгечә, бик кызык узды. Ярминкәдә 5-8 сыйныфлар һәм 10 нчы сыйныфлар катнашты. Һәр сыйныф, җирәбә буенча, бер халыкның милли ризыкларын һәм милли киемнәрен, гореф - гадәтләрен тасвирларга тиеш иделәр. Һәр сыйныф та бик әзерләнгән иде. Милли ризыклары телне йотарлык, киемнәре искиткеч зәвыкле иде.

Әти-әниләр, укытучылар ярминкәдә тәкъдим ителгән товарларны яратып алдылар. Ярминкә сатучыларга да, сатып алучыларга да онытылмас мизгелләр бүләк итте. Барысы да ярминкәдән бик канәгать калды.

## “Ел укучысы-2020”

Һәр ел саен укучылар арасында “Ел укучысы” бәйгесе уздырыла. Анда иң талантлы, бар яктан килгән укучыларыбыз көч сынаша. Быел да бу бәйгедә талантлы, акыллы, белемле, теләсә кайсы хәлдән җиңел генә чыгу юлын белүче оста укучылар катнашты. Алардагы энергиягә, креатив идеяләренә, белемгә омтылышларына, эшкә иҗади якын килә белүләренә, спортны, тормышны ратуларына сокланырлык иде.

Укучылар берничә минутлык чыгышлары вакытында тормышны, туган якны ратуларын шигырь, җыр, күргәзмәгә куелган эшләре аша ачып бирделәр.

Мәктәбебезнең 4А сыйныфы укучысы Гайнетдинова Камалия әлеге бәйгедә катнашып, шәһәр турының район этабында җиңеп, Гран-при алды. Без аны тәүге җиңүе белән котлыйбыз, киләчәктә аңа уңышлар теләп калабыз.

## Бадминтон ярышлары

11 нче март көнне Казан шәһәре укучылары арасында бадминтон буенча ачык шәхси һәм команда беренчелегенә ярышлар уздырылды.

Ярыш Татарстан Республикасының бадминтон федерациясе тарафыннан расланган кагыйдәләр буенча үткәрелде.

Шәхси беренчелектә егетләр һәм кызлар арасында 3 урын билгеле булды.

Призлы урыннарны алган уенчылар грамоталар һәм медальләр белән бүләкләнделәр.

15 укучыбызның 11е бик яхшы нәтиҗәләргә ирешеп, җиңү яуладылар. Котлыйбыз!


## “Алга бер адым” бөтенрәсәй бәйгесе

1 нче “А” сыйныфы укучылары Прокопьева Стефания һәм Сафин Кәрим **“Алга бер адым” бөтенрәсәй бәйгесендә** катнашып, лауреат булдылар. Без укучыларыбыз белән горурланабыз. Киләчәктә аларга уңышлар телибез!

## Татарстан Республикасының юбиляр язучылары, шагыйрьләре

Татар язучысы Әмирхан Еникигә (1909-2000) **110 яшь.**
Татар шагыйрәсе Нәҗибә Сафинага (1949) **70 яшь**.
Татар язучысы һәм тәрҗемәче Миргалим Харисовка (1939) **80 яшь**.
Татар язучысы Ринат Рәхимовка (1939–1984) **80 яшь.**
Татар язучысы Вахит Имамовка (1954) **65 яшь.**
Татар шагыйре Илгиз Кәлимуллинга (1929-1989) **90 яшь.**
Татар шагыйре Әнвәр Давыдовка (1919-1968) **100 яшь.**

## Ял итеп алыйк




**Редакциянең адресы:**
420101, Казан шәһәре,
Тулпар урамы, 2
Тел. 89050229576
**Тираж** – 50 экз.
**Баш мөхәррир һәм дизайнер:**
Корчагина Яна
**Редколлегия әгъзалары:** Мәхмүтова Мәдинә, Хәйриев Самат, Вәлиева Диләрә, Мельникова Аделина, Мәхмүтова Мәликә, Хөснетдинова Камелия

***